**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«10» май 2023 ел № 37/1

“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге” Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 12 октябрендәге 28/4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 июлендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. “Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге” Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 12 октябрендәге 28/4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе) сүзләренә алыштырырга;

1.2. 18 статьяның 1 пункты «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе М.Ш. Сәхбеев